**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, Черемшан село, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25 декабрь 2024 ел** **№ 14**

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Чирмешән
авыл җирлеге Башкарма комитетының
«Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Чирмешән
авыл җирлеге башкарма комитеты
баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне
оештыру һәм шартлары турында»
2019 елның 11 апрелендәге 5 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 7 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хатын үтәү йөзеннән, авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 11 апрелендәге 5 номерлы карарына (01.11.2022 № 13, от 23.01.2023 № 2, от 20.06.2024 №7 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмә»нең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның хезмәт хакы 24500,00 сум (егерме дүрт мең биш йөз сум) күләмендә билгеләнә».

Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарылуы сакланып калганда, хезмәткәрләрнең хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2024 елның 31 декабрենә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы М.С. Гыйниятуллина